| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br><br>НУРЛАТСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br><br>НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br><br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　　　　　　　КАРАР

19.09.2019　　　　　　　　　　　　　　　　　　№ 853

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының
Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдән саклау
буенча укыту-консультация пунктларын төзү турында

«Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль законны, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Гражданнар оборонасы өлкәсендә халыкны укытуны оештыру турындагы нигезләмәне раслау турында» 2000 елның 2 ноябрендәге 841 номерлы карарын һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 21.05.2009 № 1126-р боерыгын үтәү йөзеннән, Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдән саклау буенча уку-консультация пунктларын түбәндәге урыннарда төзергә (алга таба – ГО ГТХ):

1.1. Шәһәр Мәдәният сараенда, аның хезмәт күрсәтү зонасына Нурлат шәһәрен беркетеп;

1.2. «Грани» мәдәни-ял үзәгендә, аның хезмәт күрсәтү зонасына Нурлат шәһәрен беркетеп;

1.3. Халыклар дуслыгы йортында, аның хезмәт курсәтү зонасына Нурлат шәһәрен беркетеп;

1.4. Якты Күл күпфункцияле үзәгендә (Якты Күл авылы), аның хезмәт күрсәтү зонасына Яңа Иглай, Иске Иглай авыллары, Некрасовка, Тукай поселоклары, Югары Нурлат авылын беркетеп;

1.5. Бикүле авылы мәдәният йортында (Бикүле авылы), аның хезмәт күрсәтү зонасына Бикүле, Илюткино авыллары, Березовка поселогы, Аксумла авылы, Түбән Нурлат бистәсе, Әхмәт, Ерепкино авылларын, Чишмә поселогы, Чуваш Мәнҗәсе, Осиновка авылларынн беркетеп;

1.6. Киекле авылы мәдәният йортында (Киекле авылы), аның хезмәт күрсәтү зонасына Кизләү, Үрнәк авылларын беркетеп;

1.7. Биляр-Озеро авылы мәдәният йортында (Биляр-Озеро авылы), аның хезмәт күрсәтү зонасына Зирекле авылын беркетеп;

1.8. Чулпан күпфункцияле үзәгендә (Чулпан авылы), аның хезмәт күрсәтү зонасына Гайтән, Кәкре Күл, Кара Күл авылларын, Иске Авыл, Юган поселокларын, Торнаяс, Яңа Тумба авылларын беркетеп;

1.9. Егоркино авылы мәдәният йортында (Егоркино авылы) аның хезмәт күрсәтү зонасына Единение, Каравыл Тавы, Рус Мәнҗәсе авылларын беркетеп;

1.10. Якушкино күпфункцияле үзәгендә (Якушкино авылы) аның хезмәт күрсәтү зонасына Абрыскино, Салдакай авылларын беркетеп;

1.11. Тимерлек авылы мәдәният йорты (Чуваш Тимерлеге авылы) аның хезмәт күрсәтү зонасына Стекольный, Красномайский поселокларын, Рус Тимерлеге авылын беркетеп;

1.12. Фома авылы мәдәният йортында (Фома авылы), аның хезмәт күрсәтү зонасына Биккол авылын беркетеп;

1.13. Яңа Әмзә авылы мәдәният йортында ( Яңа Әмзә авылы), аның хезмәт күрсәтү зонасына Яңа Әмзә, Иске Рус Әмзәсе, Иске Әмзә авылларын, Кызыл Юл поселогын, Чурабатыр авылын беркетеп;

1.14. Мамык авылы мәдәният йортында (Мамык авылы), аның хезмәт күрсәтү зонасына Бутаиха поселогын, Төрнәс авылын, Беренче бригада совхозы һәм Гайтән совхозы поселогын, Сәләнгеш авылын, Зүзәй авылын беркетеп;

1.15.Иске Чаллы авылы мәдәният йортында (Иске Чаллы авылы), аның хезмәт күрсәтү зонасына Урта Чаллы, Түбән Чаллы авылларын беркетеп;

1.16. Колбай-Мораса авылы мәдәният йортында (Колбай-Мораса авылы), аның хезмәт күрсәтү зонасына Көрнәле Әмзә, Кече Колбай-Мораса авылларын беркетеп;

1.17. Урта-Камышлы авылы мәдәният йортында (Урта Камышлы авылы), аның хезмәт күрсәтү зонасына Абляскино, Чияле Алан, Кече Камышлы авылларын, Михайловка, Кызыл Октябрь поселокларын беркетеп;

1.18. Андреевка авылы мәдәният йортында (Андреевка авылы ), аның хезмәт күрсәтү зонасына Богдашкино авылын, III съезд исемендәге поселокны беркетеп;

1.19. Кычытканлы авылы мәдәният йортында (Кычытканлы авылы), аның хезмәт күрсәтү зонасына Иске Әлмәт, Яңа Әлмәт авыллары, Нариман поселокларын беркетеп.

2. «Мәдәниятне үстерү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесенең структур бүлекчәләре мөдирләрен Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча уку-консультация пунктлары башлыклары итеп билгеләргә.

3. Түбәндәгеләрне расларга:

- Нурлат муниципаль районы территориясендә төзелгән гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча уку-консультация пунктларының 1нче кушымта нигезендә структурасы һәм составы;

- гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча 2нче кушымта нигезендә уку-консультация пункты башлыгы вазыйфалары.

4. Уку-консультация пунктларының составын укыту-консультация пункты башлыгы һәм 1-3 инструктор составында штаттан тыш нигездә формалаштырырга.

5. Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча уку-консультация пунктлары башлыкларына карар рәсми басылып чыкканнан соң 2 ай вакыт эчендә түбәндәгеләрне эшләргә тәкъдим итәргә:

- 2020 елга эшләмәүче халыкны укыту буенча гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча уку-консультация пунктының эш планы (алга таба- һәр елны 1 декабрьгә кадәр);

- Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча уку-консультация пунктының эш көне тәртибе;

- Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча уку-консультация пункты буенча дежур тору графигы (яртыеллык буенча);

- үткәрелгән консультацияләрне исәпкә алу журналы;

- плакатлар, уку өчен әдәбият, кулланмалар, брошюралар һәм белешмәлекләр сатып алуга гариза.

6. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлегенә, районның белем бирү оешмаларының тормыш иминлеге нигезләре укытучыларын, 1нче кушымта нигезендә Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча уку-консультация пунктларына аларның эшен оештыру өчен беркетүне гамәлгә ашырырга.

7. ТР Нурлат муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре башкарма комитетлары җитәкчеләренә әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча оештырылган уку-консультация пунктларын, укыту-матди база белән җиһазландыруда ярдәм күрсәтергә тәкъдим итәргә.

8. ТР гадәттән тыш хәлләр министрлыгы Гражданнар оборонасы өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру бүлегенең әйдәүче консультантына әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча уку-консультация пункты башлыкларына аларның эшчәнлеген оештыруда һәм гамәлгә ашыруда методик һәм гамәли ярдәм күрсәтергә тәкъдим итәргә.

9. Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча уку-консультация пунктларын булдыру чараларын финанслауны, Россия Федерациясе законнары нигезендә, ТР Нурлат муниципаль районы бюджеты хисабына тормышка ашырырга.

10. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Л.Н. Маняпов

Татарстан Республикасы Нурлат
муниципаль районы Башкарма
комитетының 2019 елның 19
сентябрендәге 853 номерлы карарына

1 нче кушымта

**Нурлат муниципаль районы территориясендә төзелгән гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча уку-консультация пунктларының структурасы һәм составы**

<table>
<tr><th rowspan="2">№ т/с</th><th rowspan="2">ГО һәм ГТХ буенча уку-консультация пункты (алга таба – ГО һәм ГТХ буенча УКП) урнашкан оешма исеме</th><th rowspan="2">Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча УКП урнашу адресы</th><th>Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча УКП башлыгы</th><th rowspan="2">Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча УКП инструкторлары</th></tr>
<tr><th>Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча УКП башлыгы урынбасары</th></tr>
<tr><td rowspan="3">1</td><td rowspan="3">«Мәдәниятне үстерү үзәге» МБУ Шәһәр Мәдәният сарае</td><td rowspan="3">423040,<br>Нурлат ш.,<br>Мәктәп ур., 3нче йорт</td><td rowspan="3">«Мәдәниятне үстерү үзәге» МБУ Шәһәр Мәдәният сарае директоры</td><td>Шәһәр Мәдәният сарае сәнгать җитәкчесе</td></tr>
<tr><td>Нурлат шәһәре «1 нче урта гомуми белем мәктәбе» МАГБУнең ТИН укытучысы</td></tr>
<tr><td>Нурлат шәһәре «2 нче урта гомуми белем мәктәбе» МАГБУнең ТИН укытучысы</td></tr>
</table>

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 2 | «Мәдәниятне үстерү үзәге» МБУ район мәдәният йорты «Грани» мәдәни-ял үзәге | 423040, Нурлат ш., Могыйнов ур., 10нчы йорт | «Грани» мәдәни-ял үзәге директоры | «Грани» мәдәни-ял үзәгенең сәнгать җитәкчесе |
| | | | | Нурлат шәһәре «4 нче урта гомуми белем мәктәбе» МАГБУнең ТИН укытучысы |
| | | | «Грани» мәдәни-ял үзәге директоры урынбасары | Нурлат шәһәре «9 нчы урта гомуми белем мәктәбе» МАГБУнең ТИН укытучысы |
| 3 | «Мәдәниятне үстерү үзәге» МБУ Халыклар Дуслыгы йорты | 423040, Нурлат ш., Завод ур., 17а йорт | Халыклар Дуслыгы йорты директоры | Халыклар Дуслыгы йорты методисты |
| | | | | Нурлат шәһәре «3 нче урта гомуми белем мәктәбе» МАГБУнең ТИН укытучысы |
| | | | | Нурлат шәһәре «8 нче урта гомуми белем мәктәбе» МБГБУнең ТИН укытучысы |
| 4 | «Мәдәниятне үстерү үзәге» МБУ Якты Күл күпфункцияле үзәге | 423007, Нурлат районы, Якты Күл авылы, Үзәк ур., 30 в йорт | Якты Күл авылы мәдәният йорты мөдире | Якты Күл авыл мәдәният йортының сәнгать җитәкчесе |
| | | | | «Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГБУнең ТИН укытучысы |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 5 | «Мәдәниятне үстерү үзәге» МБУ Бикүле авылы мәдәният йорты | 423009, Нурлат районы, Бикүле авылы, Мәктәп ур., 23 йорт | Бикүле авылы мәдәният йорты мөдире | Бикүле авылы мәдәният йорты сәнгать җитәкчесе<br>«Нурлат муниципаль районы Бикүле төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБГБУнең ТИН укытучысы |
| 6 | «Мәдәниятне үстерү үзәге» МБУ Киекле авылы мәдәният йорты | 423031, Нурлат районы, Киекле авылы, Үзәк ур., 4нче йорт | Киекле авылы мәдәният йорты мөдире | Киекле авылы мәдәният йорты сәнгать җитәкчесе<br>«Нурлат муниципаль районы Киекле урта гомуми белем бирү мәктәбе» ТИН укытучысы |
| 7 | «Мәдәниятне үстерү үзәге» МБУ Биляр-Озеро авылы мәдәният йорты | 423013, Нурлат районы, Биляр-Озеро авылы, Яшел ур., 48 а йорт | Биляр-Озеро авылы мәдәният йорты мөдире | «Биляр-Озеро урта гомуми белем бирү мәктәбе» ТИН укытучысы |
| 8 | «Мәдәниятне үстерү үзәге» МБУ Чулпан күпфункцияле үзәге | 423015, Нурлат районы, Чулпан ав., Муса Җәлил ур., 70нче йорт | Чулпан күпфункцияле үзәге мөдире | «Чулпан урта гомуми белем бирү мәктәбе» ТИН укытучысы |
| 9 | «Мәдәниятне үстерү үзәге» МБУ Егоркино авылы мәдәният йорты | 423020, Нурлат районы, Егоркино авылы, | Егоркино авылы мәдәният йорты мөдире | Егоркино авылы мәдәният йорты сәнгать җитәкчесе<br>«Нурлат муниципаль районы |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Үзәк ур., 33нче йорт | | Егоркино урта гомуми белем бирү мәктәбе» ТИН укытучысы |
| 10 | «Мәдәниятне үстерү үзәге» МБУ Якушкино күпфункцияле үзәге | 423021, Нурлатский район, Якушкино ав., Гагарин ур., 2 а йорт | Якушкино күпфункцияле үзәге мөдире | «Якушкино урта гомуми белем бирү мәктәбе» ТИН укытучысы |
| 11 | «Мәдәниятне үстерү үзәге» МБУ Тимерлек авылы мәдәният йорты | 423017, Нурлат районы, Чуваш Тимерлеге ав., Совет ур., 58нче йорт | Тимерлек авылы мәдәният йорты мөдире | Тимерлек авылы мәдәният йорты сәнгать җитәкчесе |
| | | | | «Нурлат муниципаль районы Тимерлек төп гомуми белем бирү мәктәбе» ТИН укытучысы |
| 12 | «Мәдәниятне үстерү үзәге» МБУ Фома авылы мәдәният йорты | 423012, Нурлат районы, Фома ав., Мәктәп ур., 15нче йорт | Фома авылы мәдәният йорты мөдире | Фома авылы мәдәният йорты сәнгать җитәкчесе |
| | | | | «Нурлат муниципаль районы Фома урта гомуми белем бирү мәктәбе» ТИН укытучысы |
| 13 | «Мәдәниятне үстерү үзәге» МБУ Яңа Әмзә авылы мәдәният йорты | 423027, Нурлат районы, Яңа Әмзә, Ленин ур., 12нче йорт | Яңа Әмзә авылы мәдәният йорты мөдире | Яңа Әмзә авылы мәдәният йорты сәнгать җитәкчесе |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 14 | «Мәдәниятне үстерү үзәге» МБУ Мамык авылы мәдәният йорты | 423024, Нурлат районы, Мамык ав., Тельман ур., 51нче йорт | Мамык авылы мәдәният йорты мөдире | Мамык авылы мәдәният йорты сәнгать җитәкчесе |
| | | | | «Нурлат муниципаль районы Мамык урта гомуми белем бирү мәктәбе» ТИН укытучысы |
| 15 | «Мәдәниятне үстерү үзәге» МБУ Иске Чаллы авылы мәдәният йорты | 423004, Нурлат районы, Иске Чаллы ав., Ленин ур., 6нчы йорт | Иске Чаллы авылы мәдәният йорты мөдире | Иске Чаллы авылы мәдәният йорты сәнгать җитәкчесе |
| | | | | «Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы урта гомуми белем бирү мәктәбе» ТИН укытучысы |
| 16 | «Мәдәниятне үстерү үзәге» МБУ Колбай - Мораса авылы мәдәният йорты | 423028, Нурлат районы, Колбай-Мораса ав., Ленин ур., 30нчы йорт | Колбай-Мораса авылы мәдәният йорты мөдире | Колбай-Мораса авылы мәдәният йорты сәнгать җитәкчесе |
| | | | | «Нурлат муниципаль районы Колбай-Мораса урта гомуми белем бирү мәктәбе» ТИН укытучысы |
| 17 | «Мәдәниятне үстерү үзәге» МБУ Урта Камышлы авылы мәдәният йорты | 423006, Нурлат районы, Урта Камышлы ав., | Урта Камышлы авылы мәдәният йорты мөдире | Урта Камышлы авылы мәдәният йорты сәнгать җитәкчесе |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Мәктәп ур., 39нчы йорт | | «Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» ТИН укытучысы |
| 18 | «Мәдәниятне үстерү үзәге» МБУ Андреевка авылы мәдәният йорты | 423003, Нурлат районы, Андреевка ав., К.Маркс ур., 2 нче йорт | Андреевка авылы мәдәният йорты мөдире | Андреевка авылы мәдәният йорты сәнгать җитәкчесе |
| | | | | «Нурлат муниципаль районы Андреевка төп гомуми белем бирү мәктәбе» ТИН укытучысы |
| 19 | «Мәдәниятне үстерү үзәге» МБУ Кычытканлы авылы мәдәният йорты | 423038, Нурлат районы, Кычытканлы ав., Мәктәп ур., 8нче йорт | Кычытканлы авылы мәдәният йорты мөдире | Кычытканлы авылы мәдәният йорты сәнгать җитәкчесе |
| | | | | «Нурлат муниципаль районы Кычытканлы төп гомуми белем бирү мәктәбе» ТИН укытучысы |

Татарстан Республикасы Нурлат
муниципаль районы Башкарма
комитетының 2019 елның 19
сентябрендәге 853 номерлы карарына

2 нче кушымта

# Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча укыту-консультация пункты башлыгы вазыйфалары

Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча уку-консультация пункты башлыгы (алга таба – УКП) түбәндәгеләр өчен җаваплы:

- хезмәт күрсәтү зонасында эшләмәүче халык белән консультацияләр оештыру һәм аларның барышы;
- уку процессын матди-техник яктан тәэмин итү;
- гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча УКП штатына инструкторлар сайлау, аларның һөнәри әзерлеге, консультацияләр расписаниесен үтәү.

Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча УКП башлыгы бурычлы:

- планлаштыручы һәм хисап документларын эшләргә;
- документларның үз вакытында үтәлешенең исәбен алып барырга;
- гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча УКП уку-материаль базасын камилләштерү;
- беркетелгән территориянең характеристикасын, эшләмәүче халыкның санын белү;
- эшләмәүче халыкны әзерләү буенча эшләр торышын, проблемалы мәсьәләләрне белү, халыкны әзерләүдә ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү максатыннан консультацияләр тематикасына төзәтмәләр кертү буенча үз вакытында чаралар күрергә;
- эш барышында консультация хезмәтләре күрсәтүне оештыру зонасында авыл җирлекләре башлыклары белән, шулай ук эчке эшләр министрлыгы бүлекләре, Сәламәтлек саклау, санитария-эпидемиология хезмәте белгечләрен җәлеп итү буенча һ. б. авыл җирлекләре башлыклары белән элемтә булдырырга;
- документлар эшләргә һәм беркетелгән территориянең эшләмәүче халкын укыту буенча хисап документациясен алып барырга;
- гадәттән тыш хәлләр һәм гражданнар оборонасы эшләре буенча УКП мөлкәтенең тәртибе, бөтенлеге һәм төзеклеге артыннан күзәтү.

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча уку-методик үзәге филиалларында биш елга бер тапкыр Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә квалификация күтәрү курсларын үтәргә.